# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

# К А Р А Р

19.11.2018 № 203

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

“2019 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юл-урам челтәрендәге вак таштан юл полотносына нигез салу һәм каплау: Апаз авылы Гагарин урамы 18 йорттан 46 йортка кадәр, Ашитбаш-Карадуган юлыннан Ленин урамы 2 йортка кадәр; Каратай авылы Һ.Такташ урамы 2 йорттан 5 йортка кадәр; Пөшәңгәр авылы Чапаев урамы 31 йорттан 26 йортка кадәр; Миржәм авылы Н.Сафин урамы 17 йорттан 7 йортка кадәр; Кзыл-Игенче авылы Пөшәңгәр-Кзыл-Игенче юлыннан Дальняя урамы 7 йортка кадәр; Хәсәншәех авылы Комсомол урамы 88 йорттан «Киндер Күленә» кадәр;

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урам утлары челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән, Хәсәншәех, Каратай, Апаз, Пөшәңгәр, Миржәм авылларында изолицияләнгән яктырткычлар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;

- Хәсәншәех авылында кече архитектура формаларын сатып алу һәм балалар мәйданчыгын төзекләндерү;.

3. Җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- Пөшәңгәр авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга”.

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 1449 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны-1403, бу 96,83% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 1387 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 98,86% тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 16 кеше тавыш бирде, бу 1,14% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. “2019 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге бүлектә укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, 70 яшьтән өлкәнрәк кешеләрдән 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юл-урам челтәрендәге вак таштан юл полотносына нигез салу һәм каплау: Апаз авылы Гагарин урамы 18 йорттан 46 йортка кадәр, Ашитбаш-Карадуган юлыннан Ленин урамы 2 йортка кадәр; Каратай авылы Һ.Такташ урамы 2 йорттан 5 йортка кадәр; Пөшәңгәр авылы Чапаев урамы 31 йорттан 26 йортка кадәр; Мирҗәм авылы Н.Сафин урамы 17 йорттан 7 йортка кадәр; Кзыл-Игенче авылы Пөшәңгәр-Кзыл-Игенче юлыннан Дальняя урамы 7 йортка кадәр; Хәсәншәех авылы Комсомол урамы 88 йорттан «Киндер Күленә» кадәр;

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урам утлары челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән, Хәсәншәех, Каратай, Апаз, Пөшәңгәр, Мирҗәм авылларында изолицияләнгән яктырткычлар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;

- Хәсәншәех авылында кече архитектура формаларын сатып алу һәм балалар мәйданчыгын төзекләндерү;.

3. Җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- Пөшәңгәр авылында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия булганда авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны референдумда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга”.

соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3.Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева